| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.06.2020 Баулы шәһәре № 135

Дүртенче чакырылыш Татарстан
Республикасы Баулы муниципаль
районы Баулы шәһәр Советына
депутатлар сайлау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10нчы статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23нче статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105нче статьясы 1нче өлеше, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 13 статьясы нигезендә, Баулы шәһәр Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Баулы шәһәр Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Хезмәткә дан» («Слава труду») газетасында һәм pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, кабул ителгән көннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, бастырып чыгарырга.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин